ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЮГАРЫ ПӘНӘЧЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

КАРАРЫ

№ 111 **22 сентябрь 2018 ел**

«Гражданнарның үзара салымы турында» Югары Пәнәче авыл җирлеге Советының 2014 елның 12 февралендәге 122 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Югары Пәнәче авыл җирлеге Уставына таянып, Югары Пәнәче авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. «Гражданнарның үзара салымы турында» Югары Пәнәче авыл җирлеге Советының 2014 елның 12 февралендәге 122 номерлы карары белән расланган Югары Пәнәче авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымы турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
1.1. II бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 6 пунктны өстәргә:
«6. Гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибе авыл җирлеге башкарма комитеты кабул итә торган муниципаль хокукый акт белән билгеләнә.»;
1.2. III бүлекне төшереп калдырырга.
2. Карарны җирлекнең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районы сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Совет рәисе,
авыл җирлеге башлыгы **М.Х.Туктаров**